ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында” 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2015, № 10 (I өлеш), 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

“2. Татарстан Республикасы казнасының күчемсез мөлкәте белән идарә итү, аның сакланылышын һәм максатчан кулланылышын исәпкә алу һәм тикшереп тору Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.”.

**2 статья**

“Татарстан Республикасының мәгълүмат системалары һәм аны мәгълүматлаштыру турында” 2007 елның 13 ноябрендәге 58-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 3 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 11; 2010, № 12 (II өлеш); 2014, № 4) “тарафыннан билгеләнгән тәртиптә” сүзләрен “тарафыннан билгеләнгән” сүзләренә алмаштырырга.

**3 статья**

“Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында” 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2015, № 4) “идарә итү тәртибен билгеләү” сүзләрен “идарә итү” сүзләренә алмаштырырга.

**4 статья**

“Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясындагы 4 өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 12 (I өлеш) “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты” сүзләрен “Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы” сүзләренә алмаштырырга.

**5 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2016 елның 9 июле
№ 62-ТРЗ